**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №221-43 «17» апрель 2025 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 107-19 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карары белән расланган “Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары” турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 апрелендәге 226 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында”гы карары, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакындагы карары нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 107-19 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы (28.05.2024 №181-32, 25.10.2024 №194-36 карарлар редакциясендә) карары белән билгеләнгән бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең 2025 елның 1 майдан айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2022 елның 14 декабрендәге 107-19 номерлы «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы түләү шартлары турында»гы карары белән расланган “Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы шартлары” турындагы Нигезләмәгә (28.05.2024 №181-32, 25.10.2024 №194-36 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 бүлекнең 1.4 пунктындагы беренче абзацында «13 990,00» санын «15 389,00» санына алмаштырырга;

- 2 бүлекнең 2.3 пунктының 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга;

- 2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин